**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ**

**КАРАР**

«10» 01 2022 ел Яр Чаллы № 2

Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегенең 16:39:103501:2020, 16:39:103501:1989, 16:39:103501:1990, 16:39:103501:2021, 16:39:103501:2066, 16:39:103501:2088, 16:39:103501:2052, 16:39:103501:2087 кадастр номерлы җир кишәрлекләренең рөхсәт ителгән файдалану төрен төп төрдән шартлы-рөхсәт ителгән төргә үзгәртү турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексының 35, 36, 39 статьялары, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»131-ФЗ номерлы Федераль закон, Тукай муниципаль районының Кече Шилнә авыл җирлегенең Җирдән файдалану һәм төзелеш алып бару кагыйдәләре, район уставы, Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2018 елның 29 декабрендәге вн/2 номерлы карары белән расланган Тукай муниципаль районында халык тыңлауларын оештыру һәм үткәрү тәртибе турында нигезләмә нигезендә, район һәм Кече Шилнә авыл җирлеге халкының уңайлы тормыш шартларына хокукларын, Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлеге территориясендә урнашкан җир кишәрлекләре һәм капиталь төзелеш объектлары хокук ияләренең хокукларын һәм законлы мәнфәгатьләрен үтәү максатыннан

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегенең 16:39:103501:2020, 16:39:103501:1989, 16:39:103501:1990, 16:39:103501:2021, 16:39:103501:2066, 16:39:103501:2088, 16:39:103501:2052, 16:39:103501:2087 кадастр номерлы җир кишәрлекләренең рөхсәт ителгән файдалану төрен «Торак төзелеше өчен» төп төрдән «4 каттан да биегрәк булмаган күпфатирлы торак йортлар, фатир янындагы кишәрлекләр белән яки алардан башка» шартлы-рөхсәт ителгән төргә үзгәртү буенча халык тыңлауларын үткәрергә.

2.1. Әлеге карарны районның рәсми сайтында (tukay.tatar.ru) һәм Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитетының мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

2.2. Халык тыңлауларын үткәрү турында мәгълүматны «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырып чыгарырга.

3. Халык тыңлауларын бер көндә, 2022 елның 18 февралендә 13.00 сәгатьтә үткәрергә, үткәрү урыны: Тукай районы, Кече Шилнә авыл җирлеге, Ильбухтино авылы, Икенче Яңа тыкрык ур., 2.

4. Халык тыңлауларын үткәрү өчен җаваплы итеп Тукай муниципаль районы Башкарма комитетының төзелеш, архитектура һәм халык яшәешен тәэмин итү бүлеге башлыгы урынбасары О.А. Никитинаны билгеләргә.

5. Проект буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен кушымта нигезендә расларга.

6. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Тукай муниципаль район Башлыгы Ф.М. Камаев

Тукай муниципаль районы Башлыгының 2022 елның 10.01. 2 номерлы карарына кушымта

Фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибе

Әлеге тәртип Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Кече Шилнә авыл җирлегенең 16:39:103501:2020, 16:39:103501:1989, 16:39:103501:1990, 16:39:103501:2021, 16:39:103501:2066, 16:39:103501:2088, 16:39:103501:2052, 16:39:103501:2087 кадастр номерлы җир кишәрлекләренең рөхсәт ителгән файдалану төрен төп төрдән шартлы-рөхсәт ителгән төргә үзгәртү проекты буенча фикер алышуда халыкның катнашуын тәэмин итү максатында эшләнгән һәм район гражданнарының проект буенча фикер алышуда катнашу, шулай ук халыкның фикерен исәпкә алу тәртибен җайга сала.

1. Гражданнарның проект буенча фикер алышуда катнашуы халык тыңлауларында катнашу һәм Тукай районы Башкарма комитетына район халкы тарафыннан проект буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр җибәрү юлы белән башкарыла.
2. Проектның график һәм текст материаллары Кече Шилнә авыл җирлеге Башкарма комитеты бинасында мәгълүмат стендларында урнаштырылган.
3. Проект буенча материаллар белән танышу вакыты: дүшәмбе - җомга, 9.00 сәгатьтән 16:00 сәгатькә кадәр (төшке аш 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр).
4. Проект Тукай муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырылырга тиеш (tukay.tatar.ru).
5. Проект буенча язма тәкъдимнәр һәм искәрмәләр 2022 елның 17 январеннән 2022 елның 17 февраленә кадәр түбәндәге адрес буенча кабул ителә: ТР, Яр Чаллы ш., Муса Җәлил пр., 46 йорт, Тукай муниципаль районы Башкарма комитеты бинасы, 203 кабинет.
6. Халык тыңлауларын үткәрү өчен җаваплы зат халык тыңлауларын әзерли һәм үткәрә, шулай ук проект буенча гражданнарның тәкъдимнәрен кабул итә һәм исәпкә ала.
7. Халык тыңлаулары секретаре проект буенча фикерләр, тәкъдимнәр һәм искәрмәләрне исәпкә алуны документлар белән тәэмин итә.
8. Халык тыңлаулары башланганчы, халык тыңлауларында катнашучылар секретарь тарафыннан теркәлә. Теркәү кәгазендә халык тыңлауларында катнашучыларның фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган көне, яшәү урыны күрсәтелә.
9. Халык тыңлауларын уздырганда түбәндәге регламент билгеләнә:
   - чыгыш ясаучыга төп доклад өчен 20 минутка кадәр вакыт бирелә;
   - проект буенча фикер алышу өчен – 3 минутка кадәр;
   - фикерләрне кире кагу һәм искәрмәләр өчен – 2 минутка кадәр.
10. Халык тыңлауларын үткәрү барышында секретарь тарафыннан халык тыңлаулары беркетмәсе алып барыла. Беркетмәгә халык тыңлауларын оештыручы һәм секретарь имза куя.

11. Халык тыңлауларын оештыручы халык тыңлаулары уздырылган көннән соң 2 көн эчендә халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли, анда мәҗбүри тәртиптә түбәндәгеләр күрсәтелә:

- халык тыңлауларына чыгарылган сорауның исеме;
- халык тыңлауларын үткәрү көне, вакыты һәм урыны;
- халык тыңлауларында катнашкан авыл җирлеге гражданнарының саны;
- халык тыңлаулары нәтиҗәләре буенча карар.

12. Бәяләмә халык тыңлауларын оештыручы тарафыннан имзалана һәм ул мәҗбүри рәвештә халык тыңлаулар беркетмәсе белән бергә «Якты юл» («Светлый путь») газетасында бастырылырга һәм районның рәсми сайтында, Кече Шилнә авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштырылырга тиеш.